| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 15 июнь № 404

г. Казань

2016 елда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник тәэмин итүне һәм хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрне диспансеризацияләүне оештыру турында

Халыкның инвалидлык сәбәбе һәм вакытыннан алда үлеменең төп сәбәбе булган инфекцияле булмаган хроник авыруларны (хәлләрне) һәм аларның барлыкка килү куркынычы факторларын иртә ачыклау, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник тәэмин итүне һәм хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләргә социаль ярдәм күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәге теркәлгәннәрне расларга:

2016 елда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник тәэмин итүне һәм хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрне диспансеризацияләүне оештыруга чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү тәртибе;

2016 елда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник тәэмин итүне һәм хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрне диспансеризацияләүне оештыруга норматив чыгымнар;

2016 елда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник тәэмин итүне һәм хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләр диспансеризация үткәндә мәҗбүри караулар һәм тикшерүләр исемлеге;

2016 елда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник тәэмин итүне һәм хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрне диспансеризацияләүне оештыруга хезмәтләр күләме.

2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2009 ел, 14 декабрь, 984н номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе граждан хезмәткәрләре һәм муниципаль хезмәткәрләрнең диспансеризация үтү тәртибе (17, 18, 19 пунктлардан тыш) һәм әлеге карар белән расланган 2016 елда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник тәэмин итүне һәм хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрне диспансеризацияләүне оештыруга чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү тәртибе нигезендә 2016 елда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник тәэмин итүне һәм хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрне (алга таба – хезмәткәрләр) диспансеризацияләү үткәрүне тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгына, хезмәтләр күрсәтү күләме нормативыннан һәм күрсәтелгән максатларга норматив чыгымнардан чыгып, 2016 елда хезмәткәрләрне диспансеризацияләүне оештыруга чыгымнарны финанслар белән тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

диспансеризацияләнергә тиешле хезмәткәрләр исемлеген төзергә һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына тапшырырга;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән килештерелгән календарь планнар нигезендә хезмәткәрләргә диспансеризация үткәрергә.

5. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте департаментына 2016 елның 1 июленә кадәр Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтнең кадрлар составының бердәй мәгълүмат системасын файдаланып формалашкан, фамилиясе, исеме һәм әтисе исеме, шулай ук биләгән вазыйфасы күрсәтелгән 2016 елда диспансеризация үтәргә тиешле хезмәткәрләр исемлеген Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына тәкъдим итәргә.

6. Бу караның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков